ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТИХОНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ТИХОНОВО АВЫЛЫ ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ

КАРАР

17.11. 2023 ел № 2

2024 елга гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегенең Тихоново авылы гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Тихоново авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендәге студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр бирелә торган түләүне 50%ка киметеп 500 сум күләмендә кертергә. Алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә

1. Стенд әзерләү һәм урнаштыру;
2. Зиратка койма кую өчен материаллар алу;
3. ЭЦВ-6 төяү насосын сатып алу - 2 данә.;
4. БОС өчен һава өрдергеч сатып алу;
5. Кар җыю җайланмасын сатып алу;
6. Кар чистарту;
7. Балалар мәйданчыгы элементларын сатып алу;
8. Үлән чабу;
9. Чаралар үткәрү өчен проектор сатып алу;
10. Тихоново авылында Коммунистлар, Шишкин, Тойма урамнарында асфальт өслекле юлларны һәм чокырларны төзекләндерү

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Тихоново авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Тихоново авыл җирлеге башлыгы А.М. Карманов